**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район
с.Дубъязы, ул.Ленина, д.28

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-97, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**16 октябрь 2020 г.** **№ 6**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең норматив хокукый актларын хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, Биектау муниципаль район  Дөбъяз авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчләрен югалткан дип танырга:

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2010 елның 15 октябрендәге 5 нче номерлы «Физик затларның милек салымы турында» карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2010 елның 29 декабрендәге 14 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге территориясендә җир контролен гамәлгә ашыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2011 елның 29 гыйнварындагы 17 нче номерлы «Дөбъяз авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2011 елның 06 маендагы 30 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Дөбъяз авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2013 елның 27 июнендәге 87 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының "Дөбъяз авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2020 елның 29 мартындагы 117 нче номерлы “Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирә тәмәке төтененең йогынтысыннан һәм тәмәке куллану нәтиҗәләреннән саклау турында нигезләмәне раслау хакында” карары;

Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2020 елның 08 апрелендәге 120 нче номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында” карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы А.С.Низамов